**Миндубаева Нәзирә Хәсән кызы сөйләгәннәрдән: (1962 нче елда туган).**
**Мәктәптә укытучы булып эшли**

“Мин Ю.А. Гагарин исемендәге дружинага 1973 елда кабул ителдем. Әлеге көнгә бик озак әзерләндек. Беренче укытучыбыз Вәлиева Исламия апа Харис кызы белән берлектә пионер законнарын, антны, герой пионерларның тормыш юлын өйрәндек. Менә ул көн килеп җитте. Барыбыз да тантаналы линейкага тезелдек. Безнең уң кулыбыз алга сузылган, аларга кызыл галстуклар эленгән. Галстукларны безгә алдынгы пионерлар бәйләде.

Ә бәйрәмнән соң “мине барыгыз да күрегез” дигәндәй, изүләремне ычкындырып урам буйлап галстугымны күрсәтеп кайтканым истә. Бик зур шатлык иде пионерга кабул ителү.

Шушы ук елдан тагын бер сөенечем хәтердә: яз көне пионерга кабул ителсәм, җәй көне беренче тапкыр Биләрдәге “Имәнкәй” (“Дубок”) пионер лагерена ял итәргә бардым.”

Урманасты Шынталысы